КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июнь г.Казань № 560

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясенә лаек булган гражданнарга һәм оешмаларга дипломның формасын һәм тасвирламасын, мактаулы билгенең рәсемен һәм тасвирламасын раслау турында» 2015 ел, 14 август, 594 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясенә лаек булган гражданнарга һәм оешмаларга дипломның формасын һәм тасвирламасын, мактаулы билгенең рәсемен һәм тасвирламасын раслау турында» 2015 ел, 14 август, 594 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты дипломы формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты дипломы тасвирламасының икенче - дүртенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты мактау билгесе рәсемен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты мактау билгесе тасвирламасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 август, 594 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 июнь, 560 нчы карары редакциясендә)

Форма

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты дипломы**

<table>
<tr>
<td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ<br>20__ елның _______ октябрендәге _______ номерлы<br>УКАЗЫ нигезендә<br><br>Фамилиясе<br>Исеме Атасының исеме<br>(Оешма исеме)<br><br>Татарстан Республикасында граждан<br>җәмгыяте институтларын үстерүгә<br>өлеш кертүе өчен<br><br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>ПРЕМИЯСЕ БИРЕЛДЕ<br><br>Татарстан Республикасы<br>Президенты Р.Н. МИҢНЕХАНОВ<br><br>Казан - 20_</td>
<td>УКАЗОМ<br>ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>от ___ октября 20__ года № _______<br><br>Фамилия<br>Имя Отчество<br>(Наименование организации)<br><br>за вклад в развитие<br>институтов гражданского общества<br>в Республике Татарстан<br><br>ПРИСУЖДЕНА<br>ПРЕМИЯ ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br><br>Президент Республики<br>Татарстан Р.Н. МИННИХАНОВ<br><br>Казань – 20__</td>
</tr>
</table>

Диплом рәсеме



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ
2021 елның_______ октябрендәге __________ номерлы
УКАЗЫ нигезендә

*Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш кертүе өчен*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ ПРЕМИЯСЕ БИРЕЛДЕ**

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. МИҢНЕХАНОВ

Казан - 2021

УКАЗОМ
ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
от _____ октября 2021 года №_________

*за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан*

**ПРИСУЖДЕНА ПРЕМИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Президент Республики Татарстан — Р.Н. МИННИХАНОВ

Казань - 2021

___

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 август, 594 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 июнь, 560 нчы карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе мактау билгесе рәсеме**

Турыпочмаклы калыпта сурәтләнгән аверс




Реверс




______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 август, 594 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 июнь, 560 нчы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты мактау билгесе тасвирламасы

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреаты мактау билгесе (алга таба - билге) 999 келәймле алтын белән капланган 925 келәймле көмештән әзерләнә, диаметры 34 миллиметр булган дөрес боҗра формасында.

Билгенең алгы ягында татар халык орнаментыннан әйләнмәгә урнаштырылган кояш дискы фонында уң алгы тәпиләре күтәрелгән түгәрәк калканлы канатлы барс сурәте урнашкан,аның нигезендә «Татарстан» дигән язу, канатлар җиде каурыйдан тора, калкандагы розетка сигез таҗдан тора. Медаль әйләнәсе буенча рельефлы кайма башкарылган. Кайманың аскы сул дүрттән бер өлешенә биш таҗ яфрагыннан торган дәфнә ботагы салынган.

Билгенең арткы ягында уртада «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше өчен» дигән язу урнаштырылган, ул үзәк буенча тигезләнеп урнашкан һәм рельефлы булып тора, һәм киемгә билгене беркетү өчен җайланма бар.

Билге элмәк һәм боҗра ярдәмендә 18 миллиметр биеклектәге һәм 32 миллиметр киңлектәге турыпочмаклы калып белән тоташтырыла, анда 24 миллиметр киңлектәге Татарстан Республикасы триколоры рәвешендәге муар тасмасы беркетелгән.

_______________________________